| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА МАМЫКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МАМЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Мамык ав. **КАРАР**

«14» октябрь 2024 ел № 9

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мамык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елның 18 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Тельман ур., 51а йорты адресы буенча «Нефтьче» авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Тельман, Октябрь, Крупская, Буденный, Яшьләр, Куйбышев, Кызылармия, Ворошилов, Пионер, Елга, Киров, Комсомол тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2024 елның 18 октябрендә сәгать 14 сәг.00 минутта Мамык авылы Гоголь урамы, 10 йорт адресы буенча Мамык урманчылыгы бинасы янында Мамык авыл җирлеге Мамык авылында Гоголь, Совет, Пушкин, Мичурин, Урманасты, Чапаев урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2024 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Мамык авылының Заречный тыкрыгы буенча 14нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Елга арьягы, Нефтьчеләр, Евгений Грунис, Елга арьягы тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. 2024 елның 19 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Мамык авылының Күл яны урамы буенча 5 нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Подстанция, Күл Яны, Күл Яны тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Мамык авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.
6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.
7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү.

- балалар мәйданчыгы төзү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков